Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Күкшел авыл җирлеге Советы

# КАРАР

20 ноябрь 2020 ел № 12

«Җир салымы турында» Күкшел авыл җирлеге Советының 2013 елның 13 ноябрендәге 28 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Күкшел авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Күкшел авыл җирлеге Советының 2013 елның 13 ноябрендәге 28 номерлы карарының 4 пункты (Күкшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 36 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 27 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 14 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 30 октяберендәге 28 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 34 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 35 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 19 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Күкшел авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Күкшел авыл җирлеге
башлыгы: Р.Р.Хәмидуллин

ОГРН 1021607753298
ИНН 1623002022